ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__1__» __апрель__ 2026 ел** **№ _5_**

**“2026 - 2028 елларга “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль максатчан программасы турында**

“Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “2026 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Чараларны башкаручыларга “2026 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:\\pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңасала авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.И.Сафин

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына
“01” апрель 2026 ел №5
Кушымта

**“2026 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасы**

## Гомуми нигезләмәләр

Программаның төп максаты – Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү һәм шушы нигездә тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм халыкның мәшгульлеген тәэмин итү, җитештерү, хезмәт һәм интеллектуаль потенциалын үстерү.

## Муниципаль программаның паспорты

| | |
|---|---|
| 1. Муниципаль программаның исеме | “2026 - 2028 елларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү” муниципаль программасы |
| 2. Муниципаль программаны эшләү өчен нигез | “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы |
| 3. Муниципаль Программаның муниципаль заказчысы | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. Муниципаль программаның төп максаты | - кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңайлы мохит тудыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекнең гамәлдәге субъектларын саклап калуга һәм яңаларын булдыруга ярдәм итү; |

| | |
|---|---|
| | - базарны җирле җитештерүчеләрнең товарлары һәм хезмәтләре белән баету;<br>- авыл җирлеге халкын эш белән тәэмин итү. |
| 5. Муниөипаль программаның төп бурычлары | - барлык дәрәҗәләрдә бизнес һәм хакимиятнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, җирле үзидарә органнарының, кече һәм урта эшммәкәрлек субъектларының (алга таба – субъектлар) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның (алга таба – оешмалар)үзара хезмәттәшлеге рәвешләрен һәм механизмнарын үстерү һәм камилләштерү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үсешен мониторинглау;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай җәмәгатьчелек фикере формалаштыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәтләрне) алга җибәрүдә ярдәм күрсәтү. |
| 6. Муниципаль программаның төп чараларын башкаручылар | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 7. Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2026-2028 еллар |
| 8. Муниципаль программаның максатына ирешү индикаторлары | - кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;<br>- өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру;<br>- җитештерү күләмнәрен арттыру, продукцияне сату базарын киңәйтү;<br>- җирлек территориясендә җитештерелгән товар төрләрен киңәйтү. |
| 9. Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген 6000 сум күләмендә финанслау:<br>2026 ел – 1000 сум,<br>2027 ел – 2000 сум,<br>2028 ел – 3000 сум. |

## 1 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ПРОБЛЕМАСЫНА ТАСВИРЛАМА ҺӘМ МАКСАТЫ

Кече эшмәкәрлек – икътисадның икътисадый һәм сәяси тотрыклылык, иҗтимагый үсеш, товарларның яңа төрләрен үзләштерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту өчен принципиаль әһәмияткә ия өстенлекле секторы. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә 2026 елның 1 гыйнварына 18 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты эшчәнлек алып бара.

## 2 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ СРОГЫ

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2026 елдан 2028 елга кадәр.

## 3 бүлек. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ

| N п/п | Чара исеме | Башкаручы | Финанслау күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1. Яңасала авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын мәгълүмати һәм консультацион тәэмин итү** | | | |
| 1.1. | Арча муниципаль районының рәсми сайтында Яңасала авыл җирлеге бүлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын кече һәм урта эшмәкәрлекны үстерү һәм дәүләт ярдәме турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән мәгълүмат белән тәэмин итү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты | Финанслау таләп итми |
| 1.2. | Яңасала авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Татарстан Республикасында һәм аның төрләрендә кече бизнеска дәүләт ярдәме алу мәсьәләсе буенча консультация бирү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты | Финанслау таләп итми |
| 1.3. | Яңасала авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына инвестиция проектларын формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда ярдәм итү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты | Финанслау таләп итми |
| 1.4. | Яңасала авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына салым һәм пенсия хисабын | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты | Финанслау таләп итми |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | электрон юллауда булышлык күрсәтү | | |
| 1.5. | Кече һәм урта эшмәкәрлекка арендага бирү өчен муниципаль мөлкәт реестрын төзү һәм алып бару | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты | Финанслау таләп итми |
| **2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын методик тәэмин итү** | | | |
| 2.1. | Кече бизнесны үстерүгә һәм аңа ярдәм итүгә бәйле семинарлар һәм башка чаралар үткәрүгә ярдәм итү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты Арча муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә | Финанслау таләп итми |
| **3.Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының уңай имиджын формалаштыру** | | | |
| 3.1. | Яңасала авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының район, шәһәр һәм башка күргәзмәләрдә һәм ярминкәләрдә катнашуына ярдәм итү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты Арча муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә | Финанслау таләп итми |
| 3.2. | Җирлекнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары казанышларын пропагандалау мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты матбугат басмасы белән берлектә | Финанслау таләп итми |
| **4. Кече һәм мохит эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең уңай шартларын тәэмин итү** | | | |
| 4.1. | Кече эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты Арча муниципаль районы Башкарма комитеты белән берлектә | Финанслау таләп итми |
| 4.2. | Урнаштыру Арча муниципаль районының рәсми сайтында Яңасала авыл җирлегенең кече һәм урта бизнес эшчәнлеге турында мәгълүмат бүлегендә | Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты Арча муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә | Финанслау таләп итми |

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА МАКСАТЛАРЫ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | База 2025 елдагы күрсәткеч | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 1 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 2 елы | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 3 елы |
|---|---|---|---|---|---|
| - кече эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру; | Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны | 2 | 3 | 4 | 4 |
| - өстәмә эш урыннары булдыру һәм кече бизнеста эшләүчеләр санын арттыру; | Кече һәм урта эшмәкәрек субъектларында булдырылган эш урыннары саны | 3 | 4 | 5 | 6 |
| - җирлек территориясендә җитештерелгән товар төрләрен киңәйтү. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештергән товарлар төрләре саны | 3 | 3 | 4 | 4 |

## 6 кисәк. МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ РЕСУРСЛАР

| Финанслау чыганаклары | Еллар | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 1 | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 2 | Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның 3 | Барлыгы чор эчендә муниципаль программаны |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | елы | елы | елы | гамәлгә ашыру |
| Җирле бюджет | 2026 ел<br><br>1000 сум | 2027 ел<br><br>2000 сум | 2028 ел<br><br>3000 сум | Барысы:<br><br>6000 сум |

Программа чараларын финанслау авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Бюджет акчалары күләме фаразлау характерында була һәм тиешле бюджетларның проектларын төзегәндә һәм караганда билгеләнгән тәртиптә һәр ел саен төгәлләштерелергә тиеш.